ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 40-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.А. Вострикова, А.Р. Зарипов, М.Х. Сәлахов, И.В. Терентьева тарафыннан кертелгән «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 40-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 217-VII ДС

40-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
тарафыннан кертелә

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

«$8^1$) Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру;»;

2) 3 өлештә «балаларга өстәмә белем бирүне финанс белән тәэмин итәргә,» сүзләреннән соң «спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүгә дәүләт ярдәме күрсәтергә, шул исәптән муниципаль мәгариф оешмаларында гамәлгә ашырыла торган спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне финанс белән тәэмин итәргә,» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең $8^1$ пункты һәм 3 өлеше (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының**
**3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

2024 елның 13 декабреннән үз көченә кергән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 декабрендәге 471-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – әлеге Федераль закон) белән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә уку-укыту программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләренә карый. Муниципаль районнарның, муниципаль округларның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарының мәгариф өлкәсендәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренә муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә уку-укыту программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру карый.

Әлеге Федераль закон белән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына спорт әзерлегенең өстәмә уку-укыту программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүгә дәүләт ярдәме күрсәтү, шул исәптән муниципаль мәгариф оешмаларында гамәлгә ашырыла торган спорт әзерлегенең өстәмә уку-укыту программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне финанс белән тәэмин итү хокукы йөкләнә.

Шуңа бәйле рәвештә «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.